**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Об отмене ограничительных мероприятий (карантина), установленных на территории Краснокадкинского сельского поселения муниципального образования «Нижнекамский муниципальный район» в связи с ее неблагополучием по заболеванию бешенством животных**

В связи с истечением 60 календарных дней после уничтожения последнего трупа больного восприимчивого животного и проведением противоэпизоотических и профилактических мероприятий, в соответствии со статьей $3^1$ Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» **постановляю:**

1. Отменить ограничительные мероприятия (карантин), установленные в связи с неблагополучием по заболеванию бешенством животных на территориях личного подсобного хозяйства гражданина Исламова Минненаиля Нурулловича по улице Центральная, дом 4, села Красная Кадка в Краснокадкинском сельском поселении муниципального образования «Нижнекамский муниципальный район» и Краснокадкинского сельского поселения муниципального образования «Нижнекамский муниципальный район».

2. Признать утратившим силу Указ Президента Республики Татарстан от 28 апреля 2021 года № УП-324 «Об установлении ограничительных мероприятий (карантина) на территории Краснокадкинского сельского поселения муниципального образования «Нижнекамский муниципальный район» в связи с ее неблагополучием по заболеванию бешенством животных».

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
03 июля 2021 года
№ УП-540

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**«Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Кызыл Чапчак авыл җирлеге территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында**

Котыру чиренә бирешүчән соңгы авыру хайванның үләксәсе юкка чыгарылган көннән 60 календарь көн узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Кызыл Чапчак авыл җирлегендә Кызыл Чапчак авылы Үзәк урамы 4 нче йортта урнашкан гражданин Исламов Миңненаил Нурулла улы шәхси ярдәмче хуҗалыгы һәм «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Кызыл Чапчак авыл җирлеге территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Кызыл Чапчак авыл җирлеге территориясендә хайваннар котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2021 елның 28 апрелендәге ПУ-324 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 03 июль
№ ПУ-540